**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423747, Киров авылы,
Киров урамы 52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**СОВЕТ КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**13 май 2024 ел** **№7**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында»гы карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Законының 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Кировавыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Актаныш муниципаль районы Киров җирлеге Советы карары проектын хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. Расларга:

- «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуы турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча, 2024 елның 29 маенда, 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Киров авылы, Киров урамы, 39 йорт адресы буенча «Киров авыл мәдәният йорты» МБУ бинасында ачык тыңлаулар уздырырга .

4. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының « Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге тәртиптә эшче төркеме төзергә:

Магданов И.Х.. - Киров авыл җирлеге башлыгы

Галлямова Ф.М. - Киров авыл җирлеге секретаре

Касимов Р.М. - Киров авыл җирлеге депутаты

Хамидуллин А.Р.. - Киров авыл җирлеге депутаты

Суровцева. - Киров авыл җирлеге депутаты.

5. Эшче төркеменә ачык тыңлаулар уздыруны, күрсәтелгән карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында»Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау, ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Киров авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе И.Х.Магданов

Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге
Советының «13» май 2024 ел №7
карарына 1 нче кушымта

КАРАР ПРОЕКТЫ

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашуы турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясына, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Киров авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кушымта нигезендә кабул итәргә.

2. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының 2011 елның 05 маендагы 6 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын үз көчен югалткан дип танырга, түбәндәге үзгәрешләр кертелгән карарлар белән:

- 26.02.2021 ел, №5 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Кирорв авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 05.11.2020 ел, №7 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 12.10.2020 ел, №4 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 20.03.2020 ел, №7 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 12.02.2020 ел, №4 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында»;
- 23.01.2020 ел, №2 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 13.09.2018 ел, №21 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 25.06.2018 ел, №11 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында»

- 05.03.2018 ел, № 5 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»
- 19.12.2017 ел, №35 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында»
- 22.02.2017 ел, №3 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 16.12.2016 ел, №18 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында»;
- 14.12.2015ел, №28 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 15.10.2015 ел, № 21 «Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 19.11.2014 ел, №17 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 15.10.2014 ел, №13 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»;
- 13.05.2011 ел, №6 «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карар проекты хакында».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: https://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә авыл җирлекләре бүлегендә https://aktanysh.tatar.ru/ Kirovskoe selskoe-poselenie һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында түбәндәге адрес буенча: Татарстан республикасы,Актаныш муниципаль районы, Киров исемендэге совхоз поселогы, Киров урамы,52 йорт та урнаштырырга.

4. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Киров авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе И.Х.Магданов

Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге Советының
«13» май 2024 ел №7 карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проектына тәкъдимнәр, Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Киров авылы, Киров урамы, 52 йорты, язма рәвештә кушымтада бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| N т / б | Статья, пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Проектның тексты төзәтмәләрне исәпкә алып | Төзәтмә авторы Ф.И.О., адресы, телефоны, эш (уку)урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 7 сәгать 30 минуттан 17 сәгатькә кадәр, карар игълан ителгән көннән бер ай эчендә кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яки почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Киров авылы, Киров урамы, 52 йорты (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «ачык тыңлаулар» билгесе белән), шулай ук 3-44-47 факсы буенча.

Гаризаларлар 7 сәгать 30 минуттан 17 сәгатькә кадәр ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Киров авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе И.Х.Магданов

Актаныш муниципаль районы
Киров авыл җирлеге Советының
«13» май 2024 ел №7 карарына
3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында»Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба – ачык тыңлаулар) Киров авыл җирлеге Советының 2013 елның 21 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә үткәрелә.
2. Шулай ук, җирлек Советына ачык тыңлаулар уздыру датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гариза тапшырган җирлек халкы үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен ачык тыңлауларда катнашучы булып тора ала.
3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булмаган барлык кызыксынган кешеләр дә катнаша ала.
4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.
5. Ачык тыңлауларда рәислек итүче булып җирлек башлыгы яки аның кушуы буенча җирлекнең башка вазыйфаи заты тора.
6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча, җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.
8. Төп доклад белән эшче төркеме әгъзасы чыгыш ясый.
9. Ачык тыңлауларында катнашучылар чыгыш ясау хокукы белән гариза бирү вакытына бәйле рәвештә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чират тәртибендә чакырыла.
10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артык түгел.
11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүченең рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.
12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына кысылырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
13. Ачык тыңлаулар уздырганда тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.
14. Катнашучылар ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.
15. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне төгәлләштерү өчен сүз бирергә мөмкин.
16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм ачык тыңлаулар

беркетмәсенә кушып бирелә. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имза сала һәм ул җирлек Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркеме тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гамәлдәге кануннарда билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Ачык тыңлауларны оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Киров авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе И.Х.Магданов